**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 апрель № 265

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тыныч тормышта һәм сугыш вакытында Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы эшләвен тәэмин итү комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм комиссия составын раслау хакында» 2006 ел, 26 декабрь, 641 нче карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тыныч тормышта һәм сугыш вакытында Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы эшләвен тәэмин итү комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм комиссия составын раслау хакында» 2006 ел, 26 декабрь, 641 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 27 июнь, 453 нче; 2011 ел, 22 апрель, 321 нче; 2012 ел, 13 апрель, 301 нче; 2013 ел, 21 май, 332 нче; 2014 ел, 21 май, 339 нчы; 2014 ел, 26 декабрь, 1032 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Тыныч тормышта һәм сугыш вакытында Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы эшләвен тәэмин итү комиссиясе составын бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\265.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2006 ел, 26 декабрь, 641 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 18 апрель, 265 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы эшләвен
тәэмин итү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Здунов Артем Алексеевич | Татарстан Республикасының икътисад министры – Комиссия рәисе |
| Таркаева Наталья Александровна | Татарстан Республикасының икътисад министры урынбасары – Комиссия рәисе урынбасары |
| Орлов Андрей Николаевич | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы урынбасары – Комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гатауллова Диләрә Миңнеәхмәт кызы | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә караган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү бүлеге баш белгече-эксперты – Комиссия сәркатибе (килешү буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдреева Юлия Ивановна | Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары – социаль өлкәнең тотрыклылыгы буенча төркем җитәкчесе |
| Аполлонов Владимир Леонидович | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының урман эшкәртү, азык-төлек сәнәгате һәм җиңел сәнәгать бүлеге башлыгы – матди-техник тәэмин итүнең тотрыклылыгы буенча төркем җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Әхмәтшин Алмаз Сәлим улы | Татарстан Республикасының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары – торгызу эшләрен үткәрүгә әзерләнү буенча төркем җитәкчесе |
| Багров Юрий Николаевич | Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрының беренче урынбасары – идарә һәм элемтә системаларының тотрыклылыгы буенча төркем җитәкчесе |
| Гыйбадуллин Илдар Заһир улы | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә караган гражданнарны яклау идарәсе башлыгы – яраштыру һәм үзара хезмәттәшлек итү буенча төркем җитәкчесе (килешү буенча) |
| Егоров Андрей Вячеславович | Татарстан Республикасының транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары – транспорт системасының тотрыклылыгы буенча төркем җитәкчесе |
| Миңгалиев Илдар Равил улы | Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары – сәнәгатьнең тотрыклылыгы буенча төркем җитәкчесе |
| Сәйфетдинов Марат Мөхәммәтгали улы | Татарстан Республикасының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары – торак-коммуналь хуҗалыкның тотрыклылыгы буенча төркем җитәкчесе |
| Сафиуллин Дамир Һарун улы | Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары – ягулык-энергетика комплексының тотрыклылыгы буенча төркем җитәкчесе |
| Фатыйхов Илдар Разин улы | Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры урынбасары – сәламәтлек саклау системасының тотрыклылыгы буенча төркем җитәкчесе |
| Хаҗипов Нәҗип Нәкыйп улы | Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары – авыл хуҗалыгы җитештерүенең тотрыклылыгы буенча төркем җитәкчесе. |